ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

30.12.2025 № 964

**2026 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга раслрга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымтада бирелгән норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,85 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2026 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив

чыгымнарны раслау турында» 2025 елның 29 октябрендәге 794 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесенең 30.12.2025
№964нче номерлы карары
белән расланды

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга елга сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | укытуның өчьеллык срогы | укытуның дүртьеллык срогы | укытуның бишьеллык срогы | укытуның җидееллык срогы | укытуның сигезьеллык срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | 104 247 | 99 756 | 101 088 | 116 348 | 118 295 | 157 454 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 52 078 | 44 324 | 41 001 | 45 254 | 103 657 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 101 666 | 82 983 | 85 697 | 358 407 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 45 469 | | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 105 731 | 101 809 | 102 618 | 173 253 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 171 693 | | 157 939 | | | 275 771 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 81 056 | 73 192 | 75 802 | 75 771 | 77 485 | 112 534 |